**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Верхнестярлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл жирлеге Советы БАШЛЫГЫ**

ул. Советская, д.32г, с. Верхнее Стярле,
423314 Азнакаевского муниципального района
Тел.факс (8-5592) 42-6-18,
VSt..Azn@tatar.ru

Совет урамы, 32г, Югары Стәрле авылы, 423314
Тел.факс (8-5592) 42-6-18,
VSt.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» ноябрь 2023 ел № 14

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең Югары Стәрле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам**:**

1.Югары Стәрле авылы Беренчемай урамы 1 йорттан 62 йортка кадәр, Тынычлык урамы 1йорттан 29 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Югары Стәрле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 2023 елның 24 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта билгеләргә.

1.1 Югары Стәрле авылы Совет урамы 1 йорттан 64Б йортка кадәр,Октябрь урамы 1 йорттан 56 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Югары Стәрле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 2023 елның 24 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта билгеләргә.

1.2.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Югары Стәрле авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 24 ноябрь 2023 ел 09.00 сәг.тән 10.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 24 ноябрь 2023 ел 11.00 сәг.тән 12.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Югары Стәрле авылы, Совет ур. , 32г йорт, Югары Стәрле авыл мәдәният йорты залы;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда Югары Стәрле авыл җирлеге Югары Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, беренче төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан , махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләрдән тыш Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны икенче төркем инвалидлар өчен 250 сум итеп билгеләргә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Стәрледә юлларны тигезләү ( килешү буенча түләү);

- Югары Стәрледә юлларны кардан чистарту ( килешү буенча түләү);

- Югары Стәрле авылы урамнарны яктырту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Югары Стәрле авылында халык күплэп ял итэ торган урын “Сабантуй” мэйданын төзеклэндерү( сэхнэ, беседка, капка, бизэу тасмалары сатып алу, торба баганалар сатып алу һәм урнаштыру) һәм мэйдан яннарын төзеклэндерүне оештыру(чүп үләннәреннән чистарту хезмәтләре күрсәтү);

- Балалар мэйданчыгы сатып алу;

- Югары Стәрле авылы “Мирас” парк территориясен төзеклэндерүне оештыру (территорияләрне чүп үләннәреннән чистарту, агачлар һәм куаклар, чәчәкләр утырту (килешү буенча түләү);

- Беренчел пожар куркынычсызлыгы буенча чаралар ( ДЕПО корылмасына ремонт эшлэре: тозелеш материаллары сатып алу хэм тозеклэндеру хезмэте курсэту (килешу буенча тулэу)

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Совет ур., 32г, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Совет ур., 57 Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Беренчемай ур., 30 , Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Тынычлык ур 16,Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Октябрь ур., 39А Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Октябрь ур., 9 адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык: Л.С.Сабирҗанова